**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ**

423740, Актаныш авылы, Ленин пр., 17нче йорт. Тел. 3-44-44, факс 3-44-14

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН ГЛАВА АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423740, село Актаныш, пр. Ленина, дом 17. Тел. 3-44-44, факс 3-44-14

КАРАР ПОСТАНОВЛЕНИЕ

от ______________ 09.02.2024 ПГ-4 № ____________

**«Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының Ситуация үзәген төзү һәм Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының Ситуация үзәге турында нигезләмәне раслау хакында» район Башлыгының 2020 елның 28 июлендәге ПГ-24 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Кадрлар үзгәрешләренә бәйле рәвештә,

**КАРАР БИРӘМ:**

1. «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының Ситуация үзәген төзү һәм Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының Ситуация үзәге турында нигезләмәне раслау хакында» Актаныш муниципаль районы Башлыгының 2020 елның 28 июлендәге ПГ-24 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы ситуация үзәге җитәкчесе вазыйфаларын Башкарма комитет җитәкчесенең икътисад буенча урынбасарына йөкләргә»;

- 4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының ситуация үзәге администраторы итеп Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад һәм фаразлау бүлеге башлыгын билгеләргә»;

- 5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының ситуация үзәге мәгълүмат ресурсларын саклау һәм яклау өчен җаваплы итеп Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының мәгълүматлаштыру һәм мәгълүмат куркынычсызлыгы секторы мөдирен билгеләргә».

2. «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының Ситуация үзәге турындагы нигезләмәләр» 1.2 пунктның алтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«ситуация үзәге администраторы - Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад һәм фаразлау бүлеге башлыгы, ул ситуацион үзәк эшчәнлеген тәэмин итә»;

«Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының Ситуация үзәге турындагы нигезләмәләр» 4.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1 Актаныш муниципаль районының Ситуация үзәге администраторы булып Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад һәм фаразлау бүлеге башлыгы тора».

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Муниципаль район Башлыгы** **Л.Р. Зарипов**